**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» март 2022г. с. Тюлячи № 30

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Финанс-бюджет палатасының 2022 елның 17 февралендәге 01-14/14 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына (2020 елның 12 октябрендәге 439 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) 1 пункт:
- өченче абзацта «компенсация түләүләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;
- бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

Б) 5 пункт:
- 1 пунктчада «50 процентка кадәр» сүзләрен «8 процентка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;
- 3 пунктчада «25 процент күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер» сүзенә алмаштырырга;
- 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Хезмәт җиңел автомобильләре йөртүчеләренә түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмәне:

- I класслы йөртүчеләргә – машина йөртүче сыйфатында эшләнелгән вакыт өчен айлык тариф ставкасының билгеләнгән 5 проценты;

- II класслы йөртүчеләргә – машина йөртүче буларак эшләнелгән вакыт өчен айлык тариф ставкасының 2 проценты.»;

- 6 пунктчаның өченче абзацында «35 процент күләмендә» сүзләрен «7 процент күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

- 6 пунктчаның бишенче абзацында «50 процентка кадәр» сүзләрен «10 процентка кадәр күләмдә» сүзләренә алмаштырырга.

в) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, тариф ставкаларын түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш, түбәндәге түләүләр өчен чаралар каралган (бер елга исәпләгәндә):

1) Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмәләр - бер айлык тариф ставкасы күләмендә.

2) Йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмәләр, нормалаштырылмаган эш көне өчен – бер бөтен уннан сигез айлык тариф ставкасы күләмендә.

3) Эш нәтиҗәләре буенча премияләр – бер айлык тариф ставкасы күләмендә.

4) Еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм күрсәтү – бер айлык тариф ставкасы күләмендә.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин